**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАКАРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422602 село Ташкирмень ,
ул.Мира, д.40
тел: 8(84378)-4-85-25
факс: 8(84378)4-85-25

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МАКАРОВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
МУНИЦИПАЛЬ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ**
422602 Ташкирмән авылы
Тынычлык урамы, 40 нчы йорт,
тел: 8(84378)-4-85-25
факс: 8(84378)-4-85-25

---

**2021елның 24 сентябре** **13 номер**

**КАРАР**

**«2021 елга Лаеш муниципаль районының «Макаровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә коррупциягә каршы көрәш чаралары планын раслау турында»**

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының «2021-2024 елларга Коррупциягә каршы көрәшнең милли планы турында» 2021 елның 16 августындагы 478 номерлы Указы, «Татарстан Республикасында коррупциягә каршы тору турында "2006 елның 4 маендагы 34-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә һәм Макаровка авыл җирлегенең коррупциячел хокук бозуларны профилактикалау эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыру максатларында, Макаровка авыл җирлеге Башкарма комитеты **карар итә**:

1. «Макаровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә коррупциягә каршы көрәш чаралары планын кушымта нигезендә расларга.
2. Карарны мәгълүмат стендларында һәм Лаеш муниципаль районының: http:/ laishevo.tatarstan.ru. рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

.

**Макаровка авыл җирлеге Башкарма
комитеты җитәкчесе** **Кормачев В.В.**

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Макаровка авыл җирлеге Башкарма комитетының 2021 елның 24 сентябрендәге 13 нче карарына кушымта.

**2021 елга Макаровка авыл җирлегендә коррупциягә каршы көрәш чаралары планы.**

| Бүлекләр һәм пунктлар | Чаралар | Башкару сроклары | Җаваплы |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| **1. Коррупциягә каршы тору эшчәнлеген хокукый җайга салуны камилләштерү һәм оештыру ягыннан тәэмин итү өлкәсендә чаралар** | | | |
| 1.1. | Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча муниципаль хокукый актларны Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән тәңгәлләштерү | Ел буе | Авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе |
| 1.2. | Коррупциягә каршы экспертиза үткәрү:<br>-муниципаль хокукый актлар проектлары;<br>- муниципаль хокукый актлар проектлары; | Ел буе | Башкарма комитет сәркатибе Юридик бүлек башлыгы |
| 1.3. | Коррупциягә каршы тору буенча Лаеш муниципаль районы башлыгы каршындагы комиссия белән үзара хезмәттәшлекне тәэмин итү | Ел буе | Авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе |
| 1.4. | Коррупциягә каршы тору өлкәсендә хокук саклау органнары белән хезмәттәшлекне тәэмин итү | Ел буе. | Авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе |
| 1.5. | Расланган административ регламентлар нигезендә муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең сыйфаты турында халык арасында мониторинг (сораштыру) үткәрү . | Даими | Авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе |
| 1.6. | Гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшне оештыруны камилләштерү. Гражданнарны кабул итү графигын раслау. | Даими | Авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе, Башкарма комитет |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | сәркатибе |
| 1.7. | Җирле үзидарә органында коррупция фактлары турында гражданнарның шикаятьләрен һәм мөрәҗәгатьләрен анализлау һәм күрсәтелгән фактларны тикшерү (булганда) | кварталга 1 тапкыр | Авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе |
| **2. Кадрлар сәясәтен камилләштерү чаралары** | | | |
| 2.1. | Тикшерүләр үткәрү һәм коррупциягә каршы тору максатларында билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны һәм бурычларны үтәмәү, муниципаль хезмәткәрләргә кагылышлы чикләүләрне бозу очраклары буенча тиешле юридик җаваплылык чараларын куллану. Эш башкару артыннан контрольне көчәйтергә. | Үтәмәү факты билгеле булганда | Авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе |
| 2.2. | Муниципаль хезмәткәрләр өчен хезмәт тәртибенә һәм хезмәт этикасына карата таләпләрне, коррупцион хокук бозулар һәм җинаятьләр өчен административ һәм җинаять җаваплылыгы мәсьәләләрен аңлату буенча киңәшмәләрдә катнашу | Ел буе | Авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе |
| 2.3. | Муниципаль хезмәткәрләрнең коррупциягә каршы тору максатларында билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны һәм бурычларны үтәү буенча, шул исәптән бүләкләр алуга кагылышлы чикләүләрне үтәү буенча оештыру, аңлату һәм башка чаралар комплексын гамәлгә ашыру | Ел буе | Авыл җирлеге ашкарма комитеты җитәкчесе |
| 2.4 | Муниципаль хезмәткәрләрнең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре һәм чыгымнары турында мәгълүматларны үз вакытында тутыру һәм тапшыру эшен оештыру | 2021 елның 30 апреленә кадәр | Авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе |
| **3. Муниципаль заказны урнаштыру өлкәсендә эшчәнлекне камилләштерү чаралары** | | | |
| | | | |
| 3.1. | Сатуларны планлаштыру исәбенә сатып алулар планын үтәүне тәэмин итү, еллык план-графикны раслау (мөмкин булган үзгәрешләрне исәпкә алып) һәм аны «Интернет»челтәрендәге рәсми сайтка урнаштыру | Ел буе | Авыл җирлеге хисапчысы |
| **4. Халыкка мәгълүмат бирү буенча чаралар** | | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 4.1 | Авыл җирлеге территориясендә учреждениеләрдә һәм оешмаларда коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча аңлату эшләре алып бару | Ел буе | Глава СП, руководители учреждений и организаций (по согласованию) |
| 4.2. | Авыл җирлеге, мәгариф учреждениеләре, мәгълүмат стендларында һәм «Интернет» челтәрендә Коррупциягә каршы тору буенча кабул ителә торган муниципаль хокукый актларны урнаштыру | Ел буе | Секретарь Исполнительного комитета |
| 4.3. | Хуҗалык китапларыннан өземтәләр бирүне контрольдә тотарга. | Ел буе | Глава СП |
| 4.4. | Коррупциягә каршы тору буенча халык арасында аңлату эшләре алып бару, мәдәният һәм мәгариф бүлеге белән берлектә чаралар. Халыкара коррупциягә каршы көрәш көненә багышланган түгәрәк өстәлләр , әңгәмәләр үткәрү. «Хәбәрдарлык тартмалары» н гражданнарга язмача мөрәҗәгать итү өчен учреждениеләрдә урнаштыру. | Квартал саен | Глава СП, руководители учреждений и организаций (по согласованию) |